**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» мартыннан №43-331

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2023 елдагы эшчәнлеге һәм 2024 елга бурычлары турында хисабы

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 56 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәнең 19 статьясы нигезендә Контроль-хисап палатасы рәисе Р. А.Губкинның Контроль-хисап палатасының 2023 елдагы эшчәнлеге һәм 2024 елга бурычлары турында хисабын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2023 елдагы эшчәнлегенең хисабы һәм 2024 елга бурычлары турында хисабын игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районын Контроль-хисап палатасының 2023 елдагы эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

3. 2024 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасына:

3.1. Җирле үзидарә органнарын тотуга киткән чыгымнарны да кертеп, бюджет ассигнованиеләрен бюджетның барлык статьялары буенча тотуның законлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә контрольлек итәргә;

3.2. Муниципаль берәмлек мике белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тотарга;

3.3. Муниципаль ихтыяжларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрергә;

3.4 Бюджет проектлары буенча экспертиза үткәрү һәм нәтиҗәләр бирү,район һәм авыл җирлекләре бюджеты үтәлеше буенча хисаплар бирү буенча эш алып барырга;

3.5. Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары хокукый актларына һәм аларның проектларына финанс-икътисадый экспертиза үткәрергә;

3.6. Вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, авыл җирлекләре Башкарма комитетларына, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1. Бюджет акчаларын, муниципаль милекне макатчан кулланмауны булдырмаска, шул исәптән ягулык-майлау материалларын, аларны тулысынча нәтиҗәле куллануны тәэмин итәргә (хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү, билгеләнгән чыгым нормативларын үтәү);

4.2. Мөлкәткә һәм башка салымнар, кредиторлык (дебиторлык) бурычлары буенча вакыты чыккан недоимканы булдырмау чараларын үткәрергә;

4.3. Бухгалтерлык исәбе, финанс хисаплылыгы торышына һәм финанс-бюджет дисциплинасы дәрәҗәсенә аерым игътибар бирергә, аларның дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар күрергә;

4.4. Муниципаль сатып алулар өлкәсендә законнар таләпләрен үтәүне, шул исәптән сатып алуларның нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

4.5. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга финанс ярдәме күрсәтүнең билгеләнгән тәртибен сакларга;

4.6. Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклануны оештыруда билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

4.7. Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә эчке финанс контролен камилләштерү буенча эш алып барырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов